**СОВЕТ**
**НОВОШЕШМИНСКОГО**
**СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ**
**НОВОШЕШМИНСКОГО**
**МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА**
**РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН**
ул. Советская, д.80,
с. Новошешминск,423190

**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ**
**ЯҢА ЧИШМӘ**
**МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫНЫҢ**
**ЯҢА ЧИШМӘ**
**АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ**
**СОВЕТЫ**
Совет урамы, 80,
Яңа Чишмә авылы,423190

тел.: (8-84348) 2-20-08, факс: (8-84348) 2-21-73, Nsmsp.Nsm@tatar.ru

Татарстан Республикасы Яңа Чишмә муниципаль районы
Яңа Чишмә авыл җирлеге Советы
КАРАРЫ

2022 елның 14 декабре — № 24-88

Татарстан Республикасы Яңа Чишмә муниципаль районы Яңа Чишмә авыл җирлеге Советы депутаты статусы турында Татарстан Республикасы Яңа Чишмә муниципаль районы Яңа Чишмә авыл җирлеге Советы карары белән расланган Нигезләмәгә үзгәрешләр кертү хакында 16.09.2022 №22-84

"Россия Федерациясендә җирле үзидарәне оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законнар, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законы, Татарстан Республикасы Яңа Чишмә муниципаль районының “Яңа Чишмә авыл җирлеге” муниципаль берәмлеге Уставы, Яңа Чишмә муниципаль районының Яңа Чишмә авыл җирлеге Советы

КАРАР БИРӘ:

1. Татарстан Республикасы Яңа Чишмә муниципаль районы Яңа Чишмә авыл җирлеге Советы депутаты статусы турында Татарстан Республикасы Яңа Чишмә муниципаль районы Яңа Чишмә авыл җирлеге Советының 16.09.2022 №22-84 карары белән расланган Нигезләмәгә түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1.1. 3 статьяның 1 пунктындагы 13 пунктчасын төшереп калдырырга;

1.2. «Муниципаль берәмлек» сүзләреннән соң 9 статьяның 2 пунктында «Татарстан Республикасы Яңа Чишмә муниципаль районының Яңа Чишмә авыл җирлеге (алга таба – җирлек)» сүзләрен өстәргә;

1.3. 10 статьяның 1 пунктында «Татарстан Республикасы Яңа Чишмә муниципаль районы» сүзләрен «Җирлек» сүзе белән алыштырырга;

1.4. 10 статьяның 3 өлешенең икенче җөмләсен төшереп калдырырга;

1.5. 15 статьяның беренче абзацында «Татарстан Республикасы Яңа Чишмә муниципаль районының “Яңа Чишмә авыл җирлеге” муниципаль берәмлеге» сүзләрен «Җирлек» сүзе белән алыштырырга;

1.6. 17 статьяның 1 өлешендәге 10 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«10) үз керемнәре, мөлкәтләре һәм мөлкәти характердагы йөкләмәләре турында мәгълүмат, шулай ук гамәлдәге законнар нигезендә хатынының (иренең) һәм балигъ булмаган балаларының керемнәре, чыгымнары, мөлкәтләре һәм мөлкәти характердагы йөкләмәләре турында белешмәләр бирергә.»;

1.7. 20 статьяның 1 пунктында «Татарстан Республикасы Яңа Чишмә муниципаль

районы» сүзләрен «Җирлек» сүзе белән алыштырырга.

2. Әлеге карарны «Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында» Интернет «мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә бастырып чыгарырга: http://pravo.tatarstan.ru шулай ук рәсми сайтта Яңа Чишмә муниципаль районы сайтында Татарстан Республикасы муниципаль берәмлекләре порталында «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә урнаштырырга: http://novosheshminsk.tatarstan.ru.

3. Бу карар рәсми басылып чыкканнан соң көченә керә.

4. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны Татарстан Республикасы Яңа Чишмә муниципаль районы Яңа Чишмә авыл җирлеге Советының законлылык, экология, җирдән файдалану, торак-коммуналь хуҗалык һәм территорияне төзекләндерү мәсьәләләре буенча даими депутат комиссиясенә йөкләргә.

Татарстан Республикасы
Яңа Чишмә муниципаль районы
Яңа Чишмә авыл җирлеге Башлыгы

В. М. Козлов